| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЬМЕТЬЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘЛМӘТ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» февраль 2026 ел г. Альметьевск № 223

**Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2023-2025 елларга Әлмәт муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм саклауның муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 22 декабрендәге 3090 номерлы карарына үзгәрешләр**

«2023-2025 елларга Әлмәт муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту» муниципаль программасын финанслау лимитларын төгәлләштерү белән бәйле рәвештә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2023-2025 елларга Әлмәт муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм саклауның муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 22 декабрендәге 3090 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 18 декабрендәге 8098 номерлы, 2024 елның 26 ноябрендәге 3750 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарга 1 нче кушымтада:

Программа паспортының «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | - Муниципаль Программаны финанслауның гомуми күләме Әлмәт муниципаль районы бюджеты хисабына 7мең 228 сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2023 елда - 3,980 мең сум;<br>2024 елда - 2,548 мең сум;<br>2025 елда – 0,7 мең сум.<br><br>Искәрмә: күрсәтелгән чыганаклардан бүлеп бирелгән акчалар күләме фаразлау характерында була һәм, программалы чаралар исемлеген, аларны гамәлгә ашыру срокларын һәм этапларын ирешелгән |

заказ № 4553-940

| | |
|---|---|
| | нәтиҗәләр нигезендә төгәлләштерүне исәпкә алып, билгеләнгән тәртиптә җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертергә тиеш. |

2 бүлекнең 2.3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3.1. Алдынгы технологияләр нигезендә хезмәтне саклау хезмәткәрләрен укыту.

Куелган бурычларны хәл итүнең нәтиҗәсе булып «Җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәтне саклау буенча узган укулары - 41 кеше» индикаторы күрсәткеченә ирешү тора;

2023-2025 елларга Әлмәт муниципаль районында хезмәт шартларын яхшырту һәм хезмәтне саклау буенча муниципаль программа таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Программа нәтиҗәләре һәм программа чаралары буенча финанслау
БӘЯЛӘҮ МАКСАТЛАРЫ, БУРЫЧЛАРЫ, ИНДИКАТОРЛАРЫ

Таблица

| Максат исеме | Бурыч исеме | Төп чаралар исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары (бер. үлчәү) | Индикаторлар әһәмияте | | | Финанслау чыганагын күрсәтеп финанслау (мең сум) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Куркынычсызлык һәм гигиена таләпләрен тәэмин итә торган хезмәтне саклауга һәм хезмәт шартларына дәүләт гарантияләрен тәэмин итү | Заманча технологияләр нигезендә хезмәтне саклау хезмәткәрләрен әзерләү; | Хезмәтне саклау буенча җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен һәм белгечләрен укытуны оештыру | Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты | 2023-2025 еллар | Җитәкчеләр һәм белгечләр (кеше) укуын узган кешеләр саны | 8 | 26 | 7 | 3,980 | 2,548 | 0,7 |
| | Хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропагандалау | Массакүләм мәгълүмат чараларында хезмәтне саклау мәсьәләләрен пропагандалау (хезмәтне саклау буенча норматив документларның оператив мәгълүматын бастырып чыгару һ. б.) | | | Җитештерү травматизмы һәм бәхетсезлек очракларының дәрәҗәсенең кимүе % | 5 | 10 | 15 | | | |

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары

Муниципаль программа чаралары Татарстан Республикасы Әлмәт

муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. 2023-2025 елларга Программаны финанслау күләме 7 мең 228 сум тәшкил итә, шул исәптән:

2023 елда - 3,980 мең сум;

2024 елда - 2,548 мең сум;

2025 елда – 0,7 мең сум.

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында һәм, җирле бюджет мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш».

2023-2025 елларга Әлмәт муниципаль районында хезмәт шартларын һәм хезмәтне саклауны яхшырту муниципаль программасына 1 нче кушымта таблицасында:

1 юлның 8 графасында «10,000» саннарын «0,7»саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары И.И. Сәлимгәрәевка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов